ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ

ИСКЕ УЗИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР

№ 74 09 ноябрь 2018 ел

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Узи авыл җирлеге Советының«Физик затлар милкенә салым турында»2015 елның 19 октябрендәге 7 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында.

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлегенә, Россия Федерациясе Бюджет Кодексының 64 статьясына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Узи авыл җирлеге Советы карары:

1. ТР Аксубай муниципаль районы Иске Узи авыл җирлеге Советының «Физик затлар милкенә салым турында " 19.10.2015 № 7 карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

2 нче пунктның 2 нче пунктының 3 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) 0,2 процент: фатирлар; фатир өлешләре; бүлмәләр;

3) торак йортларга; торак йортларның өлешләренә; төзелеп бетмәгән объектларга карата, әгәр мондый объектларның проектлана торган максаты торак йорт булса; бер генә булса да торак йорт кергән Бердәм күчемсез комплексларга карата 0,3 процент".

2. Физик затларның милкенә салым түләүдән азат итү:

18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнар;

18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнарның балигъ булмаган балалары;

3.Әлеге карарның гамәлдә булуын 2015 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә җәелдерергә.

4.Әлеге карар 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, әмма ул игълан ителгәннән соң бер айдан да иртәрәк түгел.

5.Әлеге карарны Иске Узи авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга һәм
Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://Aksubaevo.tatarstan.ru.

6. Әлеге карарны контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Аксубай муниципаль районы

Иске Узи авыл җирлеге

Советы Рәисе: : Н.В.Айдова